«Рассмотрено» ___________
Руководитель ШМО Сабирова Н.А.
Протокол №1
от «28» августа 2024 г.

«Согласовано» ___________
Заместитель директора по УР
Гайнутдинова Н.Р.

«Утверждаю» ___________
Директор школы Сабитов Р.Н.
Приказ № 102
от «23» августа 2024 г.

МБОУ «Камско-Устьинская татарская средняя
общеобразовательная школа имени Файзрахмана Салаховича Юнусова»
Камско-Устьинского муниципального района Республики Татарстан

**Рабочая программа по внеурочной деятельности**
**«Туган телем – татар теле»**
**для учащихся 9 класса**

Учитель Хайруллина Алсу Фидаилевна,
первая квалификационная категория

Рассмотрено на заседании
педагогчисекого совета
Протокол № 1
от «23» августа 2024 г.

2024 – 2025 учебный год

**Аңлатма язуы**

Бик борынгы чорда барлыкка килгән риторика фәненең бер тармагы – стилис-тика – XX гасыр башларында мөстәкыйль фән буларак формалашып җиткән.Кешене сөйләм теленең нинди булуы, нәрсә турында һәм ничек сөйләве һәрвакыт кызыксындырган. Нәкъ менә стилистика фәне сөйләмне дөрес оештыру юлларын, фикерне иң дөрес һәм кирәкле сүзләр ярдәмендә әйтеп бирү ысулларын, ягъни сөйләм – фикерләү культурасының төп нигезләрен өйрәнә. Кешеләрнең үзара аралашып яшәве һәм тормышның үзгәреп торуы аркасында, телнең сүз байлыгы арта.Сүзлек запасы арткан саен, кешенең сөйләме эчтәлекле, аңлаешлы һәм матуррак була бара. Телнең сүзлек составында кешеләрнең тормыш тәҗрибәсе, аларның образлы фикер йөртү сәләте, үткенлеге, зирәклеге чагыла. Халык, сүз осталары туган телнең хәзинәсеннән һәр сүзне яратып, аның күптөрле төсмерләрен табып, бер-берсе белән аңлашу өчен дә, шигъриятле сурәт ясау өчен дә файдаланалар. Билгеле бер тәртиптә төзелгән, шул телдә кабул ителгән, һәркемгә аңлаешлы таныш сүзләр, кешене үзен чолгап алган мохит белән белән таныштырып, аның актив үзгәртүчесе итәләр; хезмәткә, кеше көченә,матурлыкка дан җырлыйлар; уй- тойгылыр уяталар, хисләргә тәэсир итәләр.

Туган телебезнең тарихы, киләчәге турында борчылган заманада аны тиешенчә өйрәнү, туган телебезнең сүзлек хәзинәсеннән дөрес файдалана белү- һәркайсыбызның изге бурычы. Туган телдә дөрес сөйләү һәм язу, фикерне ачык, аңлаешлы итеп белдерә алу кешенең гомуми культурасының иң әһәмиятле өлешен тәшкил итә.

Телне өйрәнү аша кешенең гомумкультура дәрәҗәсе күтәрелә, бала эстетик таләпчәнрәк, зәвыклырак була. Халыкның иң зур байлыгы - аның теле. Кешенең бөтен аңлы тормышы аның туган теле аркылы үтә.

Тел байлыгы җитмәү аркасында, укучылар башка фәннәр буенча да материалны эзлекле итеп бирә алмыйлар. Нинди өлкәдә эшләсәк тә, безнең сөйләмебез үскән, сүз байлыгыбыз аралашу өчен җитәрлек булырга тиеш. Бүгенге көндә аралаша белү, матур итеп фикереңне әйтә, сөйли, ышандыра белү бик мөһим. Сөйләм теленең чуар булуы язу теленә дә тәэсир итә. Укучы уйлый, уйлана белә торган, язма һәм сөйләм культурасы үскән шәхес булып тәрбияләнергә тиеш.

**Программаның актуальлеге:**

Урта мәктәптә “ Татар теле һәм әдәбияты программасын”нда стилистикага өлешчә урын бирелә. 9 нчы сыйныфта укучылар татар теле дәресләрендә стильләрнең үзенчәлекләре турында 2-3 сәгать дәвамында танышып китсәләр дә, мәктәп программасында стилистика буенча тулы белем бирү каралмаган. Бу фәнгә кагылышлы теоритик белемнәрне тирәнәйтү,

фәнни яктан анализлау, ныклы күнекмәләр булдыру һәм аларны гамәли тормышта дөрес кулланырга өйрәтү бу курсның нигезендә ята.

**Программаның төп максаты:**

Рухи хәзинәләребезне барлап, милли сәнгатебезнең гүзәллеген,тарихыбызның бөеклеген күрсәтүдә телебез төп рольне уйный. Туган телебез – искиткеч бай, матур һәм тирән аһәңле тел. Аның бөтенлеген, байлыгын,сәнгать чараларын сурәтләү, чараларының үзенчәлеген күрсәтү, сөйләм телен үстерү һәм камилләштерүгә ярдәм итү – бу курсның төп максаты.

**Программаның төп бурычлары.**

- Сөйләм культурасының төп аспектлары белән таныштыру.
- Сөйләмдә сүзнең төп роле һәм әһәмияте турында аңлату.
- Телнең функциональ стильләре турында аңлату.
- Матур әдәбият стиле һәм гади сөйләм теленең үзенчәлекләре белән таныштыру.
- Образлы сурәтләү чаралары. Стилистик фигуралар һәм тропларның үзенчәлекләрен, аларны сөйләмдә дөрес куллануның әһәмиятен аңлату.
- Әңгәмә һәм аның төрле тармаклары, әңгәмә кору үзенчәлекләре белән таныштыру.
- Практик дәресләрне оештыру үрнәкләре белән таныштыру.
- Укучыларның акыл һәм хыялын, зәвыгын, сөйләм культурасын, иҗади хезмәткә омтылышын тәрбияләү.
- Укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыруга ярдәм итү.

**Программаның эчтәлеге**

**Кереш.** Курсның төп максаты, бурычлары, актуальлеге турында.
Библиографик чыганаклар белән танышу.

**I бүлек.** Стилистика фәне үзенчәлекләре. Телнең функциональ стильләренә характеристика бирү. Матур сөйләм сәнгатенә хас билгеләр, хәзерге сөйләм теле этикасы нормалары. Сүзнең асылы, сөйләмдә аның төп роле.
Логик эзлекле, эмоциональ, ышандырырлык бербөтен мәгънәгә ия булган сөйләм телен үстерү.

Матур әдәбият стиле, стилистик бизәкләр. Төшенчәләрне белдерүдә синонимнарның роле. Образлы сөйләмдә капма-каршылыклы белдерүнең махсус чарасы буларак – антоним. Төшенчә һәм образ. Сүзнең эчке формасы һәм образлылык.

**II бүлек**. Сөйләм культурасы. Сөйләм фигуралары – синтаксик конструкцияләрнең үзенчәлекле формалары.
Антитеза(төшенчәләрне капма –каршы куеп, фикер,фраза тудыру) һәм градация
(төшенчәләрнең мәгънәләре үсә һәм кими бару тәртибендә урнашуы) үзенчәлекләре.
Оксюморон(образны капма-каршылыклы күренешләрнең бердәмлеге аша сурәтләү) – үткен мәгънәле фикерне оештыручы фигура.

Риторик эндәш һәм сорау – сөйләмдә әһәмиятле мәгънәви позицияне билгеләү, тыңлаучының фикерен үзең теләгәнчә формалаштыру өчен кулланыла торган фигуралар.
Инверсия күренеше-иң киң таралган стилистик фигура, аның әһәмияте.
Анафора һәм эпифораның төп үзенчәлекләре.

**III бүлек**. Көнкүреш сөйләм теленең кулланылыш сферасы, лексика составы. Дублет һәм күрсәткеч сүзләрнең сөйләмдә кулланылышы һәм урыны. Гади сөйләм теленең синтаксик һәм морфологик төзелеше.

**IV бүлек.** Интервью. Әңгәмә кора белүнең әһәмияте. Әңгәмә төрләре, аларның үзенчәлекләре, аның төп модельләре.

**V бүлек.** Сөйләм этикасы нормалары. Аудиториядә чыгыш ясау үзенчәлекләре. Әңгәмә коруның төп юнәлешләре. Әзерлексез чыгыш ясауның үзенчәлекләре: үз-үзеңне тота белү(мимика), сөйләмнең төп фикерен җиткерә белү, кереш һәм йомгаклау сүзен формалаштыру.

**Укучылар белергә тиешле белем һәм күнекмәләр:**

**1.** Стилистика фәненең төп үзенчәлекләре, аның функциональ стильләре турында белергә.
2. Матур әдәбият стиленең нигезен тәшкил итүче образлы сурәтләү чаралары -ның аерым составын, элементларын, троплар һәм стилистик фигураларның төрләрен аера белергә.
3. Көнкүреш сөйләм теле белән әдәби телнең үзенчәлекләрен, лексика соста-вын, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләрен аңлата белергә.
4. Сөйләм этикасы нормаларын белергә.
5. Үзләштерелгән белемне гамәлдә кулланырга.

6. Укучылар “Стилистика” фәне буенча программада каралган белемнәрне үзләштереп, аларны гамәлдә куллана белергә тиешләр. Бу – әдәби, фәнни- публицистик характердагы текстларны анализлау, стилистик сурәтләү чараларын кулланып, төрле  жанрда иҗат итү һәм төрле темага телдән чыгыш ясый белү күнекмәләрен булдыру дигән сүз.

**Тематик  планлаштыру.**

| № п/п | Дәрес темасы | Планлаштыру | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Әдәби сөйләм стильләре турында төшенчә | | |
| 2. | Татар сөйләмә теле үсешендәге этаплар | | |
| 3. | Сүз турында төшенчә | | |
| 4. | Сүз һәм предмет | | |
| 5. | Сүз һәм төшенчә | | |
| 6. | Сүзнең лексик мәгънәсе | | |
| 7. | Сүздәге мәгънәләрнең үсеш юллары | | |
| 8. | Функциональ сөйләм | | |
| 9. | Экспрессив  сөйләм | | |
| 10 | Сәнгатьле сөйләм стиле | | |
| 11. | Лексик стилистика | | |
| 12. | Лексикологиянең тармаклары | | |
| 13. | Фразеологизмнарны төркемләү | | |
| 14. | Фразеологик берәмлекләрнең матур әдәбиятта һәм публицистикада кулланышы | | |
| 15. | Соңгы чорда татар телендә лексика һәм фразеологиянең үсеше, үзгәреше | | |
| 16. | Татар теленең килеп чыгышы ягыннан сүзлек составы | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 17. | Татар теленең кулланылыш сферасына карап сүзлек составы | | |
| 18. | Кулланылыш активлыгы буенча сүзлек составы ( актив һәм пассив сүзләр) | | |
| 19. | Хәзерге татар әдәби теле сүзлек хәзинәсенең экспрессив- стилистик катламнары. | | |
| 20. | Лексикография. Сүзлек төрләре | | |
| 21. | Сүзлекләрнең кулланылышы | | |
| 22. | Этимология | | |
| 23. | Фонетик стилистика | | |
| 24. | Сәхнә сөйләме | | |
| 25. | Сөйләм культурасы | | |
| 26. | Ишеткәнне сөйләү | | |
| 27. | Риторика – турында төшенчә | | |
| 28. | Риторика – чыгыш ясарга һәм аралашырга өйрәтүче фән. | | |
| 29. | Рәсми эндәшү формалары | | |
| 30. | Тәкъдимне, фикерне әдәпле итеп кире кагарга өйрәтү | | |
| 31. | Хәрәкәтләр,мимика һәм гәүдә тотышы | | |
| 32. | Интервью | | |
| 33. | Мәкалә | | |
| 34. | Зачет – дәрес. Хикәядән өзекләр һәм шигырьне сәнгатьле уку. | | |

.